ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“30” октябрь 2020 ел Күзкәй авылы №17

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Күзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылында 2020 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:
- юлларны ремонтлау

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күзкәй авылы, Муса Җәлил урамы, 35 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге башлыгының «Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылында гражданнар җыенын үткәрү һәм үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча билгеләү турында» 15.10.202020 ел № 13 карарын гамәлдән чыгарырга.

8. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев